ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2023 г. Заинск №1153

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләрен раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 28 пункты 1 өлешенә ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Су кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләрен расларга.
2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану кагыйдәләрен раслау турында" 2020 елның 1 нче июлендәге 277 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.М.Хазиповка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Исп. Сычева Ю.А.
Тел. 8(85558) 7-10-27

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына кушымта
26.12.2023 елдан N 1153

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШКАН ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ СУ ОБЪЕКТЛАРЫН ШӘХСИ ҺӘМ КӨНКҮРЕШ ИХТЫЯҖЛАРЫ ӨЧЕН КУЛЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясе Су кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән һәм Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен куллану өлкәсендә бердәм һәм мәҗбүри нормалар һәм таләпләр билгели.

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу кагыйдәләрдә кулланылган төп төшенчәләр:

- су объекты табигый яки ясалма сулык, су агымы яки суның даими яки вакытлыча тупланоуы су режимының характерлы формаларына һәм билгеләренә ия булган башка объект;

- яр буе полосасы - гомуми файдаланудагы су объектының яр буе линиясе буйлап җир полосасы; су объектлары өчен яр буе полосасының киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;

- гомуми файдаланудагы су объекты - дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге, әгәр су законнарында башкасы каралмаган булса, һәркем өчен мөмкин булган гомуми файдаланудагы су объекты;

- саклау зонасы – су объектының яр буена тоташкан территория, анда хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне тормышка ашыруның махсус режимы билгеләнә, су объектларының пычрануын, чүпләнүен, ләм басуны, аларның сулары саегуны булдырмау, шулай ук су биологик ресурсларын һәм хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының башка объектларының яшәү тирәлеген саклау максатларында, су объектларының су саклау зонасының киңлеге Россия Федерациясе Су кодексы белән билгеләнә;

- су объектларыннан (судан файдалану) файдалану - Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләрнең, физик һәм юридик затларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен су объектларыннан билгеле бер ысуллар белән файдалану;

- шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары- эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган шәхси, гаилә, өй ихтыяҗлары;

-яр буе саклау полосасы - хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә өстәмә чикләүләр кертелә торган су саклау зоналары чикләрендәге территория;

- агынты сулар – яңгыр, кар, инфильтрация, су сиптерү, дренаж сулары, аларны су объектларына чыгару (ташлау) аларны кулланганнан соң гамәлгә

ашырыла торган үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасыннан чыккан һәм башка сулар.

## II. Гомуми таләпләр

1. Һәр граждан, әгәр Россия Федерациясе Су кодексы, башка федераль законнарда башкасы каралмаган булса, гомуми файдаланудагы су объектларына башкалар кебек керү хокукына ия һәм аларны шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен түләүсез файдалана ала.

Гражданнар хокуклы:

- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан ял итү, туризм, спорт, Һәвәскәр балыкчылык, һәм дача кишәрлекләренә су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, әлеге кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә су объектларыннан файдалану белән бәйле башка максатларда файдалануга;

- гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосасыннан хәрәкәт итәргә (механик транспорт чаралары кулланмыйча) һәм алар янында булырга шул исәптән һәвәскәр балыкчылык һәм йөзмә чаралар өчен причал ясауга файдаланырга;

- гомуми файдаланудагы судан су законнары нигезендә файдалануны гамәлгә ашырырга.

2. Гражданнар шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдаланганда:

- су объектыннан файдалануны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләрдә гамәлгә ашыручы су кулланучыларга аларның хокукларын чикләргә, шулай ук кешеләр өчен киртә булырга һәм куркыныч тудырырга хокуклы түгел;

- су объектларын саклау кагыйдәләрен белергә һәм үтәргә тиеш;

Россия Федерациясе законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән гомуми судан файдалануның башка таләпләрен үтәргә тиеш;

3. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдаланганда түбәндәгеләр тыела:

- су объектларына пычрак агызулар һәм аларда җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән эксплуатациядән чыгарылган судноларны һәм башка йөзү чараларын (аларның өлешләрен һәм механизмнарын) күмү;

- су объектларына радиоактив матдәләр, пестицидлар, агрохимикатлар һәм кеше сәламәтлеге өчен куркыныч башка матдәләр һәм кушылмалар күләме су объектларына йогынтының мөмкин нормативларыннан артып киткән юынтык суларны агызу;

- су объектларында атом-төш материалларын, радиоактив матдәләрне күмү;

- су объектының санитария кагыйдәләренә һәм гомуми файдаланудагы су объектыннан халык сәламәтлеге өчен имин файдалану шартларына туры килүе турында санитария-эпидемиологик нәтиҗәсе булмаганда коену;

- кисәтүче яки тыя торган язулар белән махсус мәгълүмат билгеләре куелган урыннарда су коену;

- яр буе полосасында ягулык-майлау материалларын саклау;

- кер, башка мөлкәтне юу, кешеләр коену өчен билгеләнгән һәм агым буенча 500 метрга кадәр арада терлекләрне коендыру;

- транспорт чараларының (махсус транспорт чараларыннан тыш) хәрәкәте һәм туктавы, аларның юллар буйлап йөрүләреннән, юлларда һәм махсус җиһазландырылган, каты өслекле урыннарда тукталуларыннан тыш;

- автотранспорт чараларын һәм башка техниканы гомуми кулланылыштагы су объектларында һәм аларның яр буе полосасында юу;

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм халыкның сәламәтлеге өчен куркынычсызлык шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмәсе булмаганда, эчү өчен һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү максатларында су алу;

- әйләнә-тирә мохиткә зыян китерә, кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган гамәлләр кылу;

- махсус мәгълүмати билгеләрне үз белдегең белән алу, зыян салу яки юкка чыгару.

4. Кече үлчәмле судноларда йөзү өчен су объектларын куллану Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2020 елның 06 июлендәге 487 номерлы "Россия Федерациясе су объектларында кече үлчәмле суднолардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында"гы боерыгы белән билгеләнгән таләпләрне үтәп башкарыла.

5. Кеше тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китерү куркынычы янаган очракларда, радиация авариясе яки табигый-техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерелгәндә, гидроэнергетика объектларының саклау зоналарын билгеләгәндә, шулай ук федераль законнарда каралган башка очракларда, судан файдалану Россия Федерациясе Су кодексы белән каралган тәртиптә туктатылырга яисә чикләнергә мөмкин.

## III. Шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су кулланугa таләпләр

1. Эчү һәм хуҗалык-көнкүреш максатлары өчен пычранудан һәм чүпләнүдән сакланган гомуми файдаланудагы су объектлары кулланылырга тиеш, әлеге максатлар өчен гомуми файдаланудагы суның яраклылыгы законнар нигезендә санитар-эпидемиологик бәяләмәләр буенча билгеләнә.

2. Су кулланучыларга зыян китерә торган күләмдә бакча, яшелчә, дача җир кишәрлекләренә су сибү, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук су эчертү өчен, башка авыл хуҗалыгы хайваннарын карау эшләрен башкаруга су җыю тыела.

## IV. Коену өчен билгеләнгән урыннарга таләпләр

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы су объектларында кешеләрнең коенуы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Гомуми файдаланудагы су объектларыннан һәм аның янәшәсендәге территорияләрдән файдаланганда түбәндәгеләр тыела:

- тыю билгеләре һәм язулары булган щитлар (аншлаглар) куелган урыннарда коену;

- йөзеп керү чикләрен билгели торган буйкаларның (сай җирне билгели торган калкавыч) артына йөзеп чыгу;

- моторлы, җилкәнле судноларга, ишкәкле көймәләргә һәм башка суда йөзү чараларына йөзеп бару;

- катерлардан, көймәләрдән, причаллардан, шулай ук бу максатлар өчен ярашлы булмаган башка корылмалардан суга сикерү;

- су объектларын һәм яр буйларын пычрату һәм чүпләү;

- исерек килеш коену, исерткеч эчемлекләр куллану;

- үзең белән эт һәм башка хайваннарны алып килү;

- яр буенда һәм киенү-чишенү өчен кабиналарда чүп калдыру;

- бу максатларга туры килмәгән урыннарда туп белән һәм спорт уеннары уйнау, шулай ук чуму һәм коенучыларны су астыннан тоту, ялган тревога кычкыру;

- такталарда, бүрәнәләрдә, ятакларда, автомобиль камераларында һәм йөзү өчен махсус җайлаштырылмаган башка предметларда йөзү;

- су объекты территориясенә механик транспорт чарасы белән керү, шулай ук аны юу;

- су объекты акваториясенең кызгылт сары төстәге буйкалар белән билгеләнгән участогы чикләрендә гражданнарның коену урыннарына турыдан-туры якын җирдә балык тоту.

## V. Һәвәскәр балыкчылык өчен урын сайлау таләпләре

1. Татарстан Республикасының «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми файдаланудагы су объектларында һәвәскәр балыкчылык «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларны саклау турында» 2004 елның 20 декабрендәге 166-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Балык тоту тыела:

- шартлаткыч, агулый торган матдәләр, электр тогы, кадап тоту кораллары, су астында балык тоту коралларыннан тыш, ятьмәләр һәм балык тоту җиһазлары, барлык аулау конструкцияләре, кармаклы ятьмә куллану, балык күпләп җыела торган урыннарда багор, асма блесна, миңгерәйтү, заколлар һәм башка төр киртәләр урнаштыру ысуллары куллану, сулыкларны агызып балык тоту;

- халыкның күпләп һәм оешып ял итә торган урыннарында ярдан, йөзү чаралары бортыннан, су асты аучылыгы өчен корал, акваланг һәм башка автоном сулыш приборлары кулланып, уылдык чәчү чорында балык тоту.

3. Сулыкларда һәм су саклау зоналарында шартлаткыч матдәләр, агулаучы матдәләр һәм тыелган балык тоту кораллары белән, шулай ук Һәвәскәр балыкчылык тыелган яр буе зоналарында теләсә нинди балык тоту һәм су биоресурсларын тоту җиһазлары белән булу тыела.

## VI. Авыл хуҗалыгы хайваннары өчен су эчертү урыннары сайлауга карата таләпләр

1. Кешеләр коену өчен билгеләнгән урыннарда авыл хуҗалыгы хайваннарын су эчертү һәм коендыру урыны ясау тыела.

2. Авыл хуҗалыгы хайваннарының су эчү һәм коену урыннары кешеләрнең ял итү һәм коену зоналарыннан 500 метрдан да ким булмаган ераклыкта урнашкан булырга тиеш.

## VII. Халыкка һәм җирле үзидарә органнарына хәбәр итү

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су куллануны гамәлгә ашыру шартлары яки чикләү турында мәгълүмат халыкка “Зәй муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус мәгълүмати билгеләр һәм башка ысуллар ярдәмендә бирелә.

2. Татарстан Республикасы «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларындагы аварияләр һәм башка гадәттән тыш хәлләр турында милекчеләр һәм судан файдаланучылар кичекмәстән Зәй муниципаль районының бердәм кизү-диспетчерлык хезмәте аша җирле үзидарә органнарына 7-40-01 яки 112 телефоны аша хәбәр итәргә тиеш.

## VIII. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен җаваплылык

1. Әлеге кагыйдәләрне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

2. Су законнарын бозган өчен җаваплылыкка тартылган затлар хокук бозуларны бетерүдән һәм китерелгән зыянны түләтүдән азат ителми.